ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

Х. Такташа ул., 94, а/я 44, Казань, 420107

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮ, ӘЙЛӘНЕШЕ
ҺӘМ СЫЙФАТЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ
КОНТРОЛЕН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН
ЯКЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь
инспекциясе)

Һ.Такташ урамы, 94 нче йорт, Казан шәһәре, 420107

тел. (843) 278-92-00, факс (843) 278-91-92, e-mail: gosalcogol@tatar.ru, http://gosalcogol.tatar.ru,
ОКПО 42151664, ОГРН 1021602865239, ИНН/КПП 1654025044/165901001

# БОЕРЫК

12.10.2023 Казан ш. № 10-07/120

«Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет турында» Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 19.04.2018 елның 12-07/57 номерлы боерыгына үзгәрешләр керту турында

Норматив хокукый актларны законнарга туры китерү максатыннан боерык бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет турында» Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 19.04.2018 елның 12-07/57 номерлы боерыгына (06.06. 2019 елның 10-07/108 номерлы, 07.12.2021 елның 10-07/202 номерлы, 07.02. 2022 елның 10-07/11 номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органы каршындагы Иҗтимагый совет турында» 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы карарына ярашлы рәвештә, боерык бирәм:

югарыда күрсәтелгән боерык белән расланган Этил спирты, алкоголь продукциясе җитештерү, әйләнеше һәм сыйфаты буенча дәүләт контролен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы Дәүләт инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәдә:

1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Иҗтимагый советның составы һәм саны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе боерыгы белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган башкарма хакимиятнең республика органы каршындагы Иҗтимагый Советны оештыру тәртибенә ярашлы рәвештә раслана.»;

3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Иҗтимагый совет составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган башкарма хакимиятнең республика органы каршындагы Иҗтимагый советны оештыру тәртибе нигезендә формалаштырыла.»;

5.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Иҗтимагый совет утырышлары кимендә кварталга бер тапкыр үткәрелә. Иҗтимагый совет утырышларында кабул ителгән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерелә. Протоколны рәсмиләштерү вакыты Иҗтимагый совет утырышы уздырылган көннән алып җиде көннән артмаска тиеш.

Иҗтимагый совет утырышлары шулай ук башкарма орган инициативасы буенча башкарма орган тарафыннан эшләнгән норматив хокукый актлар һәм башкарма хакимиятнең республика органнары тарафыннан эшләнә торган башка документлар исемлегендә каралган норматив хокукый актлар проектларына Иҗтимагый совет нәтиҗәләрен бирү максатында үткәрелә, алар әлеге республика башкарма хакимият органнары каршындагы Иҗтимагый советлар утырышларында алдан фикер алышусыз кабул ителергә мөмкин түгел, «Әлеге республика башкарма хакимият органнары каршындагы Иҗтимагый советлар утырышларында алдан фикер алышусыз кабул ителә алмаган республика башкарма хакимият органнары тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар һәм башка документлар составын раслау турында» 29.03.2013 елның 214 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының расланган карары белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәлү өчен җибәрелә.».

2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең административ һәм суд практикасы бүлегенә бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.
3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затка әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Җитәкче** **Җ.Й. Әхмәтханов**